КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1258

2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында

Россия Федерациясе гражданнарының түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә конституциячел хокукларын тәэмин итү максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программалары турында» 2019 елның 7 декабрендәге 1610 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2020 елда Программа кысаларында күрсәтелгән медицина хезмәтләре өчен исәп-хисапларны тәмамлау 2021 елның 15 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла;

Программаны тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмалары тарафыннан мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге эшчәнлек турындагы хисаплылык законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча һәм Программаны раслаган көннән 14 көн эчендә – тиешле финанс елына финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә кертелә;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы буенча Медицина ярдәме күрсәтү өчен түләү турында тариф килешүе төзү буенча;

медицина оешмалары тарафыннан нигездә берканаллы финанслауны тормышка ашыруга мәҗбүри медицина иминияте системасы аша башкарыла торган медицина ярдәме күрсәтү өчен тарифларны һәм аңа түләү тәртибен эшләү һәм аларны вәкаләтле органга раслауга кертү буенча;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен файдаланып, рәсми сайтта Программаны һәм медицина ярдәме күрсәтүгә түләү өчен билгеләнгән тарифларны урнаштыру буенча;

2020 елның 15 февраленә кадәр медицина оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге буенча килештерелгән планнарны «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә кертүне тәэмин итү буенча.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондына Программаны тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүне «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы һәм «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарында әлеге максатларга күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырырга.

4. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин